БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 13 » февраль 2018 ел № 76

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары исемлеген раслау турында" 2016 елның 20 июнендәге 157 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында (2016 елның 6 сентябрендәге 205 номерлы, 2016 елның 30 сентябрендәге 21 номерлы, 2017 елның 31 гыйнварындагы 51 номерлы, 2017 елның 6 апрелендәге 126 номерлы, 2017 елның 9 сентябрендәге 239 номерлы, 2017 елның 21 декабрендәге 284 номерлы үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51, 55 статьяларына туры китереп, "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын шәһәр төзелеше законнары таләпләренә туры китерү турында" 2018 елның 27 гыйнварындагы 01-09-1346 номерлы Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары исемлеген раслау турында" 2016 елның 20 июнендәге 157 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. III кушымтаның "Капиталь төзелеш объектларын төзүгә (реконструкцияләүгә), төзүгә (реконструкцияләүгә) рөхсәтләрнең гамәлдә булуын озайтуга (туктатуга), капиталь төзелеш объектларын төзүгә (реконструкцияләүгә) рөхсәтләргә үзгәрешләр кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты" 8 нче кушымтасын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.2. III кушымтаның "Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты" 9 нчы кушымтасын әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.3. I кушымтаның "Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге" “Муниципаль хезмәтләр” бүлегендәге 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8. Төзелешкә рөхсәт бирү.";

1.4. III кушымтаның "Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары исемлеге" 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8. Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты.".

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе Р. И. Шакиров